КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 18 февраль г.Казань № 122

Татарстан Республикасы территориясендә «кега» транспорт тарасында китерелә торган сыра һәм сыра эчемлекләрен, сидр, пуаре, медовуханы мондый продукция әйләнешенең күзәтүчәнлеген идентификацияләү чаралары белән маркировкалау буенча эксперимент үткәрү турында

«Кега» транспорт тарасында китерелә торган сыра һәм сыра эчемлекләрен, сидр, пуаре, медовуханы мондый продукция әйләнешенең күзәтүчәнлеген идентификацияләү чаралары белән маркировкалау механизмнарын эшләү һәм апробацияләү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы территориясендә 2020 елның 1 апреленнән «кега» транспорт тарасында китерелә торган сыра һәм сыра эчемлекләрен, сидр, пуаре, медовуханы мондый продукция әйләнешенең күзәтүчәнлеген идентификацияләү чаралары белән маркировкалау буенча эксперимент үткәрергә (алга таба – эксперимент).

2. Экспериментның максаты булып тора:

«кега» транспорт тарасында китерелә торган сыра һәм сыра эчемлекләрен, сидр, пуаре, медовуханы мондый продукция әйләнешенең күзәтүчәнлеген идентификацияләү чаралары белән маркировкалау механизмнарының тулылыгын, нәтиҗәлелеген, нәтиҗәсен һәм җитәрлек дәрәҗәдә булуын апробацияләү һәм аның әйләнеше мониторингын гамәлгә ашыру;

Татарстан Республикасы территориясендә сыра һәм сыра эчемлекләрен, сидр, пуаре, медовуханы законсыз җитештерүгә һәм әйләнешенә каршы тору;

әлеге карарның 4 пунктында күрсәтелгән экспериментта катнашучылар

тарафыннан «кега» транспорт тарасында китерелә торган сыра һәм сыра эчемлекләрен, сидр, пуаре, медовуханың һәр берәмлеге буенча этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аның әйләнешен исәпкә алуның бердәм дәүләт автоматлаштырылган мәгълүмат системасында мәгълүматларны теркәүне гамәлгә ашыру»;

сыра һәм сыра эчемлекләре, сидр, пуаре, медовуха әйләнешен исәпкә алу процедураларын унификацияләү;

«кега» транспорт тарасында китерелә торган сыра һәм сыра эчемлекләрен, сидр, пуаре, медовуханың, мондый продукция әйләнешенең күзәтүчәнлеген идентификацияләү чаралары белән мәҗбүри маркировкага күчүнең фискаль максатларда (акцизлар өлешендә) максатка ярашлыгын билгеләү;

«кега» транспорт тарасында китерелә торган сыра һәм сыра эчемлекләрен, сидр, пуаре, медовуханы мондый продукция әйләнешенең күзәтүчәнлеген идентификацияләү чаралары белән мәҗбүри маркировкалау турында Россия Федерациясе законнарына үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәр эшләү.

3. Эксперимент үткәрүне тәэмин итүгә вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы итеп Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, аның әйләнешен һәм сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы Дәүләт инспекциясен билгеләргә.

4. Экспериментта катнашучылар түбәндәгеләр:

а) Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, аның әйләнешен һәм сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы Дәүләт инспекциясе (алга таба – вәкаләтле орган);

б) Алкоголь базарын җайга салу буенча федераль хезмәт (вәкаләтле орган белән килешү нигезендә);

в) Татарстан Республикасы территориясендә «кега» транспорт тарасында китерелә торган сыра һәм сыра эчемлекләрен, сидр, пуаре, медовуханы җитештерүчеләр һәм мондый продукция әйләнешендә катнашучылар (алга таба – сыра кайнату базары субъектлары) ирекле нигездә.

5. Экспериментта катнашу өчен сыра кайнату базары субъектлары экспериментта катнашу турында вәкаләтле орган белән ул раслаган форма буенча килешү төзи.

6. Вәкаләтле орган тарафыннан әлеге карарда каралган чараларны гамәлгә ашыру 2020 елга вәкаләтле органны тотуга билгеләнгән штат саны лимиты һәм финанслау күләме чикләрендә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин